СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 2-2 — 17 ноябрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 29 нчы июлендә кабул ителгән № 1-11 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Урта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 29 нчы июлендә кабул ителгән
1-11нче карары белән расланган (№ 3-31,05.06.2018ел, № 3-39, 21.03.2019елгы редакциядә) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 4.11 пунктына түбәндәге абзац өстәргә:

«-полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирә».

2.Әлеге карарның 1.1 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru)урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Б.Ф.Хасанов